Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге Советының егерме өченче утырышы

Белкино авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

31 март, 2023 ел № 63

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Питрәч муниципаль районы Белкино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Белкино авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдә) 2017 елның 12 декабрендәге 68 номерлы (2018 елның 20 сентябрендәге 24 номерлы, 2022 елның 31 мартындагы 39 номерлы, 2022 елның 13 июлендәге 47 номерлы, 2022 елның 10 октябрендәге 48 номерлы карарлар белән расланган үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 бүлегенең 2.4.1 өлеше 2.4 пункты «Территорияләрне төзекләндерүгә, тотуны оештыруга һәм җыештыруга гомуми таләпләр» не алып ташларга;

1.2. 3 бүлектә «Фасадларның һәм коймаларның, юлларның, шәхси торак йортларның, яңгыр канализациясе челтәрләренең, күзәтү һәм яңгыр коеларының, су чыгару корылмаларының, техник элемтә чараларының, тышкы яктырту объектларының, кече архитектура формаларының, стационар булмаган объектларның, төзелеш эшләре башкару урыннарының тышкы күренешенә карата алар урнашкан биналарны, корылмаларны һәм җир кишәрлекләрен тоту буенча таләпләр, җирләү урыннары, автотранспорт чараларын озак һәм кыска вакытлы саклау урыннары, юл сервисы объектларын. Торак пункт территориясен бәйрәмчә бизәү»:

а) 3.6.1 пунктының 11 пунктчасында «тимер юллар,» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3.7.2 пунктының 5 пунктчасында «һәм тимер юл» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3.11.8, 3.11.9, 3.11.10 пунктларында «(тимер юл)» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Белкино авыл җирлеге башлыгы А.Н. Меньшов